РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**РУКОВОДИТЕЛЬ БОЛЬШЕМЕТЕСКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ф.Хусни, 56 А, село Большие Метески,
422082
тел.: (884360) 54-4-40 (факс)
E-mail: Bmts.Tul @tatar.ru

ОКПО 94318062 ОГРН1061675010430

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ф.Хөсни урамы, 56 А, Олы Мәтәскә авылы,
422082
тел.: (884360) 54 -4-40 (факс)
E-mail: Bmts.Tul @tatar.ru

ИНН/КПП 1619004411/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 33** **25.07.2019**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә махсус урыннар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру һәм җиһазлау өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында»гы 2019 елның 10 июлендәге 67/516 номерлы карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

- Олы Мәтәскә авылы,Ф.Хөсни урамы, 52А йорт, ФАП бинасында мәгълүмат стенды ;

- Олы Мәтәскә авылы,Ф.Хөсни урамы, 52 йорт, кибет бинасы янында мәгълүмат стенды ;

- Югары Мәтәскә авылы, Үзәк урамы, 13А йорт бинасында мәгълүмат стенды ;

- Ямбулат авылы, М.Ногманов урамы, 18 йорт бинасында мәгълүмат стенды;

- Лесной бистәсе ,Татарстан урамы, 21 йорт бинасы янында мәгълүмат стенды ;

- Тәмте- Мәтәскә авылы, Тау асты урамы, тукталыш повильоны.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау округына җибәрергә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Олы Мәтәскә авылы,Ф.Хөсни урамы, 56А йорт, Олы Мәтәскә авыл җирлеге хакимияте бинасы адресы буенча Олы Мәтәскә авыл җирлеге мәгълүмат стендында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Олы Мәтәскә авыл

җирлеге башлыгы М.А.Валиуллин